**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Балтач авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Балтач авылы № 58 14 июнь 2022 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советының 2014елның 24 гыйнварь 71 номерлы карары белән расланган, Азнакай муниципаль районы «Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәлә вәкаләтләре кабул итү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2022 елның 14 апрелендәге 132-16 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлекләренә җирдән файдалану һәм муниципаль берәмлек төзү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләр вәкаләтләрен тапшыру турында» карарын исәпкә алып

Балтач авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге Советының 2014 елның 24 гыйнварь 71 номерлы карары белән расланган, Азнакай муниципаль районы «Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча Татарстан Республикасы Азнакай район Советының тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлеге башкарма комитетына әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтне кабул итү турында Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты белән килешү төзергә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2024 елның 31 декабренә кадәр вакытка кагыла дип билгели.

4. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru. һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач  авыл җирлеге Советының торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис Л.Л.Хәбипов